**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ РАЙОН СОВЕТЫ**
**(IV чакырылыш)**

IV чакырылыш чирата тыш утырышы
**КАРАРы**

2023 елның 07 июне № 29 Урыссу ш.т.п.

«Ютазы муниципаль районында капиталь һәм шәхси торак төзелеше объектларын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү тәртибен раслау турында Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 05.10.2006 № 6 карары үз көчен югалтуын тану хакында»

Россия Федерациясе шәһәр төзелеше кодексына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 03.08.2018 № 342-ФЗ Федераль законына, «Күпфатирлы йортларны һәм күчемсез милекнең башка объектларын өлешләп төзүдә катнашу һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының кайберләренә үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 13.07.2020 № 202-ФЗ Федераль законга, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында" 14.07.2022 № 350-ФЗ Федераль законга һәм «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм «Россия Федерациясендә тимер юл транспорты турында» Федераль законның 16 статьясындагы 2 пунктының икенче абзацының үз көчен югалтуын тану хакында" 29.12.2022 № 612-ФЗ Федераль законына ярашлы, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 28.07.2004 № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы законы, «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы" муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 10.10.2022 № 805 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карар кабул итә:

1. «Ютазы муниципаль районында капиталь һәм индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүгә һәм файдалануга тапшыруга рөхсәт бирү тәртибен раслау турында» 2006 елның 05 октябрендәге 6 номерлы Татарстан Республикасы Ютазы район Советы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Рәсми

Татарстан» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Ютазы район Советының законлылык, регламент һәм җирлекләр Советлары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Башлыгы -
Татарстан Республикасы
Ютазы район Советы Рәисе А.Ә. Шәфигуллин